**«Утар Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләре проекты турында» Утар Аты авыл җирлеге Советы карары буенча гавами тыңлаулар беркетмәсе**

2019 елның 07 июне Утар-Аты авылы 14 сәг. 00 мин.

Урын: Утар Аты авылы, Кооператив ур., 22 й.

Катнаштылар:

барлыгы: 25 кеше.

Э.И. Фәйзрахманова: Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлеге башлыгының 2019 елның 26 мартындагы 1 номерлы карары нигезендә бездә бүген Утар Аты авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар уздырыла.

Гавами тыңлаулар уздыру өчен җаваплы итеп Утар Аты авыл җирлеге башлыгы урынбасары Абдуллин Р.Г. билгеләнде.

Секретарь Э.И. Фәйзрахманова - авыл җирлегенең хокукый мәсьәләләре буенча белгеч.

Утар Аты авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү РФ Шәһәр төзелеше кодексының 5.1,30-34 ст., «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә башкарылды.

Гавами тыңлаулар датасы һәм кагыйдәләр проекты турында мәгълүмат Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, авыл җирлегенең торак пунктлары стендларында ТР, Арча районы, Утар Аты авылы, Кооператив ур., 22 йорт; ТР, Арча районы, Орнашбаш авылы, Яшьләр ур., 6 йорт; ТР, Арча районы, Кушлавыч авылы, Тукай ур.1 йорт адреслары буенча урнаштырылды.

Утар Аты авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар түбәндәге адрес буенча уздырыла: Утар Аты авылы, Кооператив ур., 22 йорт. Гавами тыңлауларга кадәр Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегендә ПЗЗ проекты буенча язма кисәтүләр һәм тәкъдимнәр кермәде. Арча муниципаль районы Утар Аты авыл җирлегенең ПЗЗ проекты буенча язма һәм телдән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү сроклары 2019 елның 06 апреленнән 06 июненә кадәр иде. Шулай ук бернинди искәрмәләр һәм тәкъдимнәр килмәде.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре муниципаль берәмлекләр территорияләрен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклау өчен шартлар тудыру максатларында эшләнә, шәһәр төзелешен зоналаштыруга керә. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү яңа генераль планны раслау, РФ Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү белән аңлатыла.

Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре түбәндәгеләрне үз эченә ала: аларны куллану һәм күрсәтелгән кагыйдәләргә үзгәрешләр кертү тәртибен; шәһәр төзелешен зоналаштыру картасын; шәһәр төзелеше регламентларын.

Абдуллин Р.Г.: Сораулар бармы? Гавами тыңлаулар барышында кисәтүләр булмады, кергән тәкъдим игътибарга алыначак. Әгәр сораулар юк икән, гавами тыңлаулар узды дип санала.

Гавами тыңлаулар үткәрү
Өчен җаваплы: Абдуллин Р.Г.
Гавами тыңлаулар секретаре: Фәйзрахманова Э.И.